Республика Татарстан
Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

А.Валеев урамы, 53нче йорт,
Илбәк авылы, Азнакай районы,
423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» апрель 2017 ел. № 3

Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге территориясендә
планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча
гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясен планлаштыру һәм манлау проекты буенча «Җәлилнефть «нефть-газ табу идарәсенең 31 ятмалы скважиналарын төзекләндерү»объекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2017 елның 16 апреленнән 2017 елның 16 маена кадәр;
- үткәрү урыны-Илбәк авылы, ә. Вәлиев ур., 50 й., Илбәк мәдәният йорты;
- 2017 елның 16 маена кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес – Илбәк авылы, ә.Вәлиев урамы, 53 йорт, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Илбәк авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясен планлаштыру һәм манлау проекты буенча «Җәлилнефть «нефть-газ табу идарәсенең 31 ятмалы скважиналарын төзекләндерү»объекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Илбәк авыл җирлеге территориясен планлаштыру проектын һәм манлау проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина